КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 сентябрь г.Казань № 846

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 13 март, 179 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктта:

3.3.14 нче пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Саклау бурычы аерым күмү урыннары, каберлекләр булган ачыкланган мәдәни мирас объектларына, истәлекле урыннарга, мәдәни мирас объектларына карата расланмый.

Истәлекле урыннар территорияләре чикләрендә урнашкан ядкәрләргә һәм ансамбльләргә карата саклау бурычлары раслана;»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3.17^1$ нче пунктча өстәргә:

«$3.3.17^1$. Милекчеләре булмаган яки милекчеләре билгеле булмаган яки милекчеләре милек хокукларыннан баш тарткан мәдәни мирас объектларына

(исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләр урнаштыруны гамәлгә ашыра;»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.19[1] нче пункча өстәргә:

«3.3.19[1]. Россия Федерациясе Президентының «Федераль (гомумроссия) әһәмияттәге тарихый һәм мәдәни мирас объектлары исемлеген раслау турында» 1995 елның 20 февралендәге 176 номерлы Указы белән расланган Федераль (гомумроссия) әһәмияттәге тарихый һәм мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән тарихый-мәдәни музей-тыюлыклар һәм музей комплекслары территорияләре чикләрендә урнашкан федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш) ансамбльләргә яки истәлекле урыннарга кертү, аларның объектлар составын билгеләү турында карар кабул итә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин